**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОШТАУЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2019 ел, 13 декабрь №197

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273 номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. 1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 августындагы 80 номерлы "Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмә хакында" карары белән расланган Апас муниципаль районы Коштаулы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8) ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырырга;

Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкармый торган депутат үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне депутат булып сайланган көннән алып, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан соң яисә даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне туктаткан көннән алып дүрт ай эчендә, шулай ук 2012 елның 3 декабрендәге 230 номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче гражданнар һәм башка гражданнарның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турындагы" Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләр гамәлгә ашырылган очракта белешмәләр тапшырган ел алдыннан килгән һәр ел өчен белешмәләр тапшыра. Хисап чорында мондый алыш-бирешләр гамәлгә ашырылмаган очракта, депутат бу хакта Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июльдәге 56 номерлы “Муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы,яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар ,муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче гражданнар керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында” законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентына хәбәр итергә тиеш була.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Апас муниципаль районының рәсми сайтында Коштаулы авыл җирлегенең бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Коштаулы авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

**Коштаулы авыл**
**җирлеге Башлыгы** **Х.Ф.Сабиров**